

Мордовия башлыгы Артём Алексеевич Здунов РМ Дәвләт Жыелышына еллык Юлламасын житкерде. Депутатларга, оешма житәкчеләренә, мәдәният һәм мәгариф вәкилләренә, жәмәгатьчеләргә, эшмәкәрләргә Кон-батыш илләренен санкция басымы шартларында тобәк vсеше остенлек-ләрен дә аталды. Тобәк икътисадына һәм сәнәгатенә аерым игътибар бирелде.

Юллама Республика мәдәният сараенда игълан ителде һәм Главабыз Артём Алексеевич Здунов Юлламасынын олешләп туган эрзя телендә сойләде. Үз республикабызда ничек яшибез һәм эшлибез, безнен алда нинди бурычлар тора, тормышны яхшырту очен нәрсә эшләргә кирәклеге турында сойләде житәкче һәм киләчәктә башкаларын да билгеләде. Артём Алексеевич Здунов һәлак булган сугышчылар истәлегенә бер минутлык тынлык игълан итте. Мобилизация турындагы хәбәрне лаеклы кабул итvчеләргә аерым рәхмәт белдерде. Республика киләчәктә дә солдатларга һәм аларнын гаиләләренә ярдәм итәргә әзер.

«Россия Президенты йокләмәсе буенча Мордовиядә икътисадны тотрык-лыландыру буенча кризиска каршы штаб эшли, тобәктә дәвләт ярдәменен йоздән артык чарасы гамәлгә ашырыла. Игътибар vзәгендә - импортны алыштыру, vзебезнен продукцияне алга этәрv моһим. Бер ел чамасы элек Мордовиянен социаль-икътисади vсеш программасы кабул ителде. Исегезгә тошерәбез, башта программаны га-мәлгә ашыруга федераль бюджеттан 5 млрд.сум каралган иде. Федераль органнар белән адреслы эш башкарылды һәм Россия Хокvмәте ярдәме белән агымдагы елда аны финанслау кvләме 7 млрд. ка кадәр арттырылды. Шунын аркасында Саранскта һәм Рузаевкада жылылык челтәрләре тозеләчәк, пассажирлар транспорты паркы янартылачак.

Программанын топ чаралары рес-публикада «Лисма» заводы тер-риториясендә беренче индустриаль парк тозvгә, инновацион һәм социаль инфраструктураны vстервгә, бизнес тарафыннан гамәлгә ашырыла торган проектларга финанс ярдәме кvрсәтvгә, чистарту корылмаларын һәм су бvлv челтәрләрен тозvгә һәм реконструкцияләvгә юнәлдерелгән. Моннан тыш, ел азагына безнен халык һәм предприятие житәкчеләре сораган Саранскны әйләнеп узу юлы тогәлләнәчәк», - диде Артём Здунов.

Илебезнен оборона сәләтен яклауга житди акчалар тотыла. Сәнәгать һәм сәvдә министрлыгына оборона сәнәгате нә эшләvче предприятиеләрнен тотрыклылыгын контрольгә алу йокләнде. Район администрацияләренә халыкка гражданнар оборонасы турында мәгълvмат бирvне контрольдә тотарга кирәк, дип ишеттерде житәкче.

Бvген регионнар белән хезмәт-тәшлеккә аерым игътибар бирелде. Мордовия продуктлары доньянын 21 иленә жибәрелә. Безнен катанка Испания, Голландия һәм башка евространнарны алыштырды. Бизнес-миссияләрне оештыру практикасы дәвам итәчәк - Президент йокләмәсен vтәv моһим.

Интеллектуаль милек олкәсен vс-терv буенча эш дәвам итә. Ел ахырына кадәр

биохимикада 2 яна цех һәм 300 яна эш урыны ачылачак. Бизнеска ярдәм итv алымнары янадан каралды. Регион Россия Федерациясе Президентынын тулы цикллы оптик жепсел житештерvне булдыру йокләмәсен vтәv каралды.



Приоритетта - халыкнын керем-нәре арту. Хезмәт хакы vсеше 20 проценттан артып китте, әмма тулаем алганда, тобәктә хезмәт хак-лары тvбән булып кала. Хезмәт базарында kvрелгән чаралар 2,5 мен хезмәткәрне эш белән тәэмин итәргә момкинлек биргән. Ләкин тагын 89 менгә якын эш бар! Февральдән башлап Мордовиядә Донбасс, Луганск, Мариупольдән 444 кеше килде - алар Мордовиянен 12 районында урнашкан. 194 кеше эшкә урнаша, әлегә 82се юк. Регион хокvмәте, предприятие житәкчеләре алдында аларны эшкә урнаштыруда ярдәм итv бурычы тора.

Мордовия икътисадынын дvрттән бер олешен агросәнәгать комплексы тәшкил итә. Продукция «Алтын коз» kvргәзмәсе экспертлары тарафыннан югары бәяләнә. Авыл хужалыгы ярминкәләре бәяләре Идел буе федераль округында ин тvбән. Фермерлар очен ин моһим мәсьәләләрнен берсе - житештерелгән продукцияне сату. Кооперацияне vстерv буенча халык белән мәгълvмати эш алып бару, ана кооператив институтны, депутатларны тоташтыру моһим.

Агросәнәгать комплексы vсеше авыл халкынын тормыш сыйфаты белән тыгыз бәйләнгән. Cvз тvләvсез юридик ярдәм турында да барды, аеруча ерак жирләрдә яшәvчеләргә.

Узган ел сәламәтлек саклауны модернизацияләv программасы башланды. Яна жиһазлар ярдәмендә онкология авыруларын ачыклауны арттыра алдык. Беренчел бурычларнын берсе- авылда медицина vсеше. Мордовия бюджетынын 15 % сәламәтлек саклау олкәсенә жибәрелә. Шул ук вакытта ел саен ташламалы категория гражданнар очен медикаментлар житмәvгә карата шикаятьләр килә. «Фармация» жәмгыятчелеге эшен тикшерергә кирәк.

«Мордовия Арена» стадионын экс-плуатацияләvнен нәтижәлелеген арттыру мәсьәләсе кискен кала. Спорт объекты башында заманча житәкче булырга тиеш. Спорт министрлыгы мона аеруча игътибар итәргә тиеш.

Тозелеш секторы Мордовия икътисадына зур олеш кертә. Киләсе елда 400 мен квадрат метр торак файдалануга тапшырылырга, кешеләрне авария хәлендәге тоpактан kvчерергә тиешләр.

Мордва телләрен vстерv програм-масынын әһәмияте турында сойлә-гәндә, Артём Здунов vзеннән башлый. Бvген vсеп килvче буын турындагы мәсьәлә аеруча моһим. Ин моһим темаларнын берсе - яшьләрнен кыйммәти юнәлешләрен формалаштыру.

Агымдагы елда тобәк һәм жирле әһәмияттәге 223 километр юл норматив хәлгә китерелгән. Мордовия догазификация дәрәҗәсе буенча Россиянен ин яхшы 5 тобәгенә керә. Агымдагы елда 3,5 меннән артык йорт газ белән тәэмин итvгә тоташа алачак. Газлаштыру дәрәҗәсе югары булуга карамастан, газ бvлv челтәрләре әлегә кадәр житмәгән торак пунктлар бар: эшне катгый рәвештә расланган планга туры китереп башкарырга кирәк.

Мордовия башлыгы аэропорт эше-нә һәм ЖКХ олкәсенә, шәһәрне тозек-ләндервгә аерым тукталды. Топ яналыкларнын берсе - дәүләт бурычын тагын да киметергә

олгерде!



Хәбәр 1 сәгать 28 минут дәвам итте. Бүген Юлламаны жентекләп ойрәнү бара һәм барлыкка килгән күпсанлы фикерләр туплана. Кайберләре түбәндә.

ООО «ЭМ-КАТ»нын генераль директоры, Россия Федерациясенен атказанган машина төзүчесе, Камиль Шавкет улы Мангутов: «Юлламада моһим тема - махсус хәрби операция һәм Донбасс халкына, мобилизацияләнгән кешеләргә һәм аларнын гаиләләренә ярдәм итүгә зур урын бирелде.

Мордовия башлыгы Артём Алексеевич Здунов үзенен Юлламасында барлык топ юнәлешләр буенча конкрет бурычларны билгеләде. Инвестицион сәясәткә, икътисадны үстерүгә, тобәктә тормыш сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән системалы карарларга басым ясалды.

Республика башлыгы чыгышында регионыбыз авыл хужалыгы, производство бүгенгесенә һәм алдагы үсешенә зур урын билгеләгән. Юлламаны хуп-лыйбыз һәм тормышка ашыру юлында без; бүген тагы бер цех тозибез, киләсе елга эшли башлаячак. Мона Россия, Мордовия үсеш фондлары (софинансирование) ярдәм итә. Шулай иттереп тагы 200 эш урыны ачылачак.

Тагы шуны әйтеп китәм, Мордовия башлыгы Артём Алексеевич Здунов үзенен Юлламасын, олешчә, ике телдә алып баруы күнелгә хуш килде».

Ләмберә региональ сайлау округы буенча Мордовия госсобрание депутаты, Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбе директоры Надия Харис кызы Заликова: «2022нче елнын 16нчы ноябрендә Мордовия Госсобраниесенен 17 кинәй-телгән утырышында регионыбыз Главасы А.А.Здунов Юллама белән чыгыш ясады.

Бүгенге Юллама республикадагы хәлне бәяләүгә һәм анын үсешендәге топ проблемаларны хәл итүнен алдагы адымнарына багышлана. Кешеләрнен тормыш сыйфатын турыдан-туры йогынты ясаучы олкәләргә аерым игътибар бирелә. Бу икътисад, финанс, социаль яклау, мәгариф һәм сәламәтлек саклау.

Главабыз Артём Алексеевич Здунов үзенен әби-бабасы сойләшкән эрзя телендә чыгышын башлау котелмәгән һәм бик тә шаккаттыргыч булды. Бу тарихынны, мәдәниятынны зурлау булуга мисал булып тора - туган теленне кадерләү, ана хормәт күрсәтү. Һәрберебез үзенен тамырларын, тарихын, мәдәниятын, туган ана телен, милли байлыкны сакларга тиеш дип саныйм: анда безнен нигез, бердәмлелек, коч!

Регионыбыз Главасы Юлламасында зур урын регионыбыз унышларына, киләчәктәге планнарга бирде. Барысын да тормышка ашырырбыз дип ышанам».

Тантаналы чарада (2нче фотода) «Якташлар» РМКАТ рәисе Р.Р.Мухаев һәм автономия әгъзалары: Р.З.Аширов, Ш.З.Бикмаев, К.Ш.Мангутов, Р.А.Фет-хуллов, Х.Ш.Якуббаев, РМ моселманнарынын Үзәк Диния нәзарәте мофтие Фагим Фатих улы Шафиев, «Чулпан» Мордовия татар хатын-кызлар оешмасы рәисе Н.Н.Азисова, Россия моселманнары Диния нәзарәте каршындагы Россия моселманнары Диния нәзарәте житәкчесе вазифаларын башкаручы Рафаэль хәзрәт Манюров катнаштылар.

Фагим Фатих улы Шафиев: «Без кочле булырга һәм, барыннан да элек, илне һәм потенциалны саклап калу очен, бергә булырга тиеш. Һәр кеше очен илне унайлы һәм куркынычсыз итәргә кирәк. Бу республика мисалында да яхшы үтәлә.

Хәзерге шартларда жәмгыятьне традицион рухи-әхлакый кыйммәтләр нигезендә

берләштерү зарур,- ди чыгышында РМ Главасы. Киләсе ел Мордовиядә Халык бердәмлеге билгесе астында узачак. Катнашучыларга РФ Президентының «Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау һәм нығыту буенча дәүләт сәясәте нигезләрен раслау турында» гы Указын кабул итү һәм аны регионда тулысынча гамәлгә ашырырга кирәклеген искәртте. XII Ботенроссия авыл Сабантуенын, «Яшь профессионаллар» конкурсының милли финалын уздыруга йомгак ясалды. РМ башлыгы коммерциячел булмаган оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә ярдәм итү очен дәүләт милли сәясәтендәге проектлар турында сойләде, торле номинацияләрдә «милли байлык» премиясен гамәлгә куюны тәкъдим итте. РМ башлыгы үз чыгышын Мордовия яшьләренә: унышлы, белемле, акыллы, үз-үзен тормышка ашыру белән шогыльләнүче яшьләргә багышлады. Алар ботенроссия конкурсларында һәм ярышларында жинеп, перспектив проектлар әзерлиләр. Нәкъ менә шуна күрә яшьләрне тәрбияләү һәм үстерүнен рухи-әхлакый компоненты дин әхелләренә моһим».

**Наилә НАСЫРОВА**